КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 декабрь г.Казань № 1217

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт контрактларын төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт контрактларын төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 25 декабрь, 1217 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт контрактларын төзү турында карарлар кабул итү
кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан арткан очракларда дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә дәүләт контрактларын төзү турында карар кабул итү тәртибен билгели.

2. Дәүләт заказчылары Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә аларны башкаруның, күрсәтүнең җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән дәүләт контрактларын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләре әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән каралган акчалар чикләрендә, әлеге карар белән каралган вакытка төзергә хокуклы

3. Дәүләт заказчылары Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә аларны башкаруның, күрсәтүнең җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән дәүләт контрактлары Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелергә мөмкин.

Мондый дәүләт контрактлары, мондый сатып алулар объектлары программаларында, һәр объектка карата, киләсе мәгълүматны күрсәтеп, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының тиешле чараларын гамәлгә ашыру өчен каралган вакыт һәм чаралар чикләрендә төзелә:

сатып алуның һәр объектына карата түбәндәге мәгълүмат күрсәтелгән:

сатып алу объектының исеме;

эшләрне башкару, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

сатып алуны гамәлгә ашыру сроклары;

башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүнең иң чик күләме еллар буенча.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм (яки) алардагы ясалма корылмаларны карап тоту һәм (яки) ремонтлау эшләрен башкаруга дәүләт контрактлары төзегәндә, аларны үтәүнең җитештерү циклы вакыты бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә, мондый дәүләт контрактлары өчен план чорыннан читтә түләүгә күздә тотылган акчаларның еллык чик күләме бюджет йөкләмәләре лимитларының максималь еллык лимитларыннан артып китә алмый, расланган төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм (яки) алардагы ясалма корылмаларны карап тоту һәм (яки) ремонтлауга агымдагы финанс елы һәм план чоры чикләрендә расланган.

5. Әлеге Кагыйдәләрнең 2 – 4 пунктларында күрсәтелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә аларны башкаруның, күрсәтүнең җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән дәүләт контрактлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән каралган вакытка һәм акчалар чикләрендә түбәндәгеләрне билгеләнгәндә төзелергә мөмкин:

эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

эшләр, хезмәт күрсәтү составы тасвирламасы;

подрядчыларны, башкаручыларны билгеләү өчен кирәкле вакытларны исәпкә алып, эшләрне башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең чик вакыты;

озак сроклы дәүләт контрактына түләү өчен акчаларның иң чик күләме еллар буенча.

6. Әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен дәүләт контракты төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе рәвешендә кабул ителә.

Әлеге карарны әзерләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын һәм аңа аңлатма язуын Татарстан Республикасының гамәлдәге дәүләт программаларына туры килү-килмәү предметына карау өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрә. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын, ул кергән көннән исәпләнгән 10 көн эчендә килештерә.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты һәм аңа аңлатма язуы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерү өчен җибәрелә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты һәм аңа аңлатма язуы кергән көннән исәпләнгән 10 көн эчендә әлеге проектны түбәндәге шартларны үтәгәндә килештерә:

төзүгә тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен дәүләт контрактының Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрына туры килүе;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән тиешле чыгым йөкләмәләрен үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен дәүләт контрактын түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең чик күләменә туры килүе;

план чоры чикләрендә күрсәтелгән контракт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең еллык максималь чик күләменнән план чоры чикләрендә күрсәтелгән контракт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең еллык чик күләмен арттырмау.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын килештерүдән баш тарткан очракта әлеге боерык проекты Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органына эшләп бетерү өчен кире кайтарыла.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

---